وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№24 (141). 15 июнь 2012 / 25-рәҗәп-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Иң мөһиме – җәмәгать күзәтчелеге ▷2◁





Халкыбызның җан сердәше – Йосыф китабы ▷3◁





Агачтан могҗиза тудыручы ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**ХОСПИС ТӨЗҮ ТУРЫНДА УТЫРЫШ УЗДЫ**

13 июнь көнне Казандагы 4 нче балалар шифаханәсенең Күзәтчелек советы утырышы узды. Утырышта ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова да катнашты.

Утырышта түбәндәге темалар буенча үзара фикер алыштылар:

1. Балалар өчен беренче хоспис проект эскизын раслау.

2. Балалар өчен беренче хоспис төзелешенә булышлык күрсәткән предприятие һәм шәхси затларга тапшырылачак рәхмәт билгесен һәм "Игелекле йөрәккә" дипломын раслау.

3. 11 палаталы бинада 18 яшьтән зуррак булган балалар өчен хоспис ярдәмен күрсәтү мәсьәләсен чишү.

4. Казандагы 4 нче балалар шифаханәсе низамнамәсенә үзгәрешләр кертү.

5. Хәйрия акцияләре үткәрү: ТР Профсоюз Федерациясе белән берлектә "Яхшылык кирпечләре", Автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы республика профсоюз комитеты хезмәткәрләре белән берлектә "Хосписны бер көндә төзибез" чаралары оештыру.

**АПАС РАЙОНЫ ҮЗӘГЕНДӘ ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛА**

17 июнь көнне сәгать унбердә (11.00) Апас районы үзәгендә яңа мәчет ачылачак. Район имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев билгеләп үткәнчә, бер ел эчендә төзелгән әлеге мәчет шәхси эшмәкәр Дамир хәзрәтнең булышлыгы белән сафка баскан.

"Күптән түгел генә манарасы куелды, бүгенге көндә мәхәллә халкын кабул итеп, мөселманнарны Аллаһ юлына чакырырга тулысынча әзербез. Мәчетнең имам-хатыйбы итеп Рамазан хәзрәт Әминов билгеләнде. Зур рәхмәтләребезне район хакимиятенә җиткерәсе килә, мәчеткә кагылышлы булган барлык мәсьәләләрне дә хәл итәргә булыштылар", - дип билгеләп үтте Мирхәт хәзрәт.

**ЛАГЕРЬЛАР ӨЧЕН КУЛЛАНМА**

Мөселман лагерьлары өчен тәүге кулланма - "Җәйге мөселман балалар лагерьлары: укыту программасы һәм үткәрү тәртибе" дип аталган китап бер ел элек дөнья күргән иде. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте әзерләде. Шушы программа узган җәй сынау үтте, хәзер исә яңа сезон ачылу алдыннан мөфтият ул брошюраны кабат бастырды. Мөселман лагерьлары оештыручылар ошбу кулланманы имам-мөхтәсибләр аша үзләрендә булдыра алалар.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*


**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**


# МИГЪРАҖ КИЧӘСЕ

**Уналтысыннан унҗиденче июньгә каршы төндә мөселманнар ислам тарихындагы гаҗәеп вакыйганы - пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) төнге сәяхәтен һәм аның күккә ашуын билгеләп үтәчәк. Бу хәл пәйгамбәребезнең (сгв) Мәккә чоры ахырында булган (якынча 619 елда).**

Моның тарихы Исра чоры вакыйгасыннан башлана (пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) Мәккәдән Әл-Коддус шәһәренә күтәрелеп алынуыннан). Мөселманнарның беренче Кыйбласы булган шәһәрдә Мөхәммәд пәйгамбәр (сгв) барлык пәйгамбәрләр һәм сәхабәләр белән бергә намаз укый, шул ук вакытта фәрештәләр пәйгамбәребезнең күкрәген ачып, йөрәген, кешеләргә хас булган гөнаһлардан һәм начар гамәлләрдән юып, чистарталар. Исра вакыйгасы түбәндәге аятьтә сурәтләнә: "Үзенең колы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗид Хәрамнан Коддус шәһәрендәге мәсҗид Әкъсага йөретеп кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Ул Коддус шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык, Мөхәммәд галәйһиссәламне гаҗәп галәмәтләребезне күрсәтмәк өчен кодрәтебез белән йөреттек, әлбәттә, Аллаһ һәр сүзне ишетүче вә һәрнәрсәне күрүчедер" ("Бәни Исраил (Ягъкуб балалары)" сүрәсе, 1 нче аять).

Күрүебезгә, пәйгамбәребез (сгв) - дөрестән дә, пәйгамбәрләрнең мөһере буларак килә. Аңа хәтле бер пәйгамбәргә дә Мигъраҗ һәм Исра кичәсендә бөтен пәйгамбәрләрнең имамы һәм рәсүле булырга насыйп булмады.

Исра вакытында пәйгамбәребезне Җәбраил фәрештә алып йөрткән: "Ул фәрештә күркәм холыклы вә матур кыяфәтле вә гаять туры һәм гакыл ияседер, заһир булды, үзенең асыл сурәте белән күренде. Ул фәрештә офыкның югарысында иде. Соңра Мөхәммәд галәйһиссәламгә якынлашты һәм югарыдан аңа сүз әйтмәк өчен сузылды. Аралары ике җәя хәтле генә калды яки аннан да якынрак булды. Җәбраил фәрештә Аллаһның колы Мөхәммәд галәйһиссәламгә үзенә Аллаһтан вәхи ителгән нәрсәне вәхи кылды. Мөхәммәд галәйһиссәламнең күңеле күргәнен ялган димәде, нык ышанды, ягъни Җәбраил фәрештәне үз сурәтендә күрде һәм Аллаһны күңеле илә күрде. Әллә Мөхәммәднең күргән нәрсәсенә шөбһә итеп низаглашасызмы? Тәхкыйк, ул Җәбраилне үз сурәтендә икенче мәртәбә күрде. Сидератүлмүнтәһә агачы янында. Мәэва җәннәте шул агач янындадыр. Ул агачны күп фәрештәләр каплаган иде. Мөхәммәд галәйһиссәламнең күзе шул агачтан һәм фәрештәләрдән читкә авышмады һәм куелган чиктән уңга-сулга үтмәде. Тәхкыйк, ул күрде Мигъраҗда Раббысының олуг галәмәт вә дәлилләрен. ("Нәҗем (Йолдыз)" сүрәсе, 6-18 нче аятьләр).

Мигъраҗ - ул пәйгамбәребезнең (сгв) күккә ашуы. Борак (җанвар) ярдәмендә ул күккә күтәрелә, күкнең һәрбер өлеше үзенең фәрештәсенә һәм пәйгамбәренә ия була. Мөхәммәд (сгв) үзе күргән барлык фәрештәләрне һәм пәйгамбәрләрне сәламли. Җәбраил фәрештә пәйгамбәребезне (сгв) җиде кат күккә хәтле алып йөрткән һәм аннан ары уза алмаган. Әлеге җиденче кат күк Аллаһ һәм кеше арасындагы соңгы чик булып тора һәм пәйгамбәребез анда Аллаһы Тәгаләдән өч әйбер турында хәбәр алган:

1) Коръәндәге "Бәкара" сүрәсенең ахыргы аятьләре иңеп беткән;

2) Аллаһны танучыларның һәм Аңа тиңдәш тотмаучыларның барысы да җәннәткә эләгәчәге турында хәбәр бирелгән;

3) Барлык мөэмин-мөселманнарга да 5 вакыт намазның фарыз булуы йөкләнелгән.

Мигъраҗ вакытында пәйгамбәребезгә Аллаһ шулай ук җәннәтне һәм җәһәннәмне күрсәтә. Ул җәһәннәмдә гөнаһлы бәндәләрнең коточкыч газаплануларын һәм җәннәттә булган мөэмин-мөселманнарның кабатланмас җәннәт бакчаларында торуларын тамаша кылган.

Бөтен дөнья мөселманнары өчен бу вакыйга - пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) олуг дәрәҗәсе һәм аның юлын исбатлаучы үрнәк булып тора. Мигъраҗ вакыйгасы Рәҗәп аеның 27 нче көнендә билгеләп үтелә. Бу көнне ястү намазының фарызыннан соң әлеге вакыйга уңае белән махсус намаз уку каралган.

Безнең сөекле пәйгамбәребез катнашында булган бу могҗиза янә бер тапкыр Аллаһның Бөеклеген искә төшерә: барысы да Аның кул астында. Пәйгамбәребез (сгв) моңа кадәр бик күп кыенлыклар кичерә һәм Аллаһ аны сабырлыгы өчен Исра һәм Мигъраҗ белән бүләкли. Искә төшерик: аның дәгъватын кабул итмиләр, сәхабәләрен үтерәләр, әмма ул ислам диненнән чыкмый. Пәйгамбәребез (сгв) барлык әлеге сынауларны уңышлы үтә һәм зур дәрәҗәләргә ирешә.

Бу мисал Аллаһ юлында булганнарга барлык авырлыклар өчен дә бүләкләүгә вәгъдә булып тора: "Дөреслектә, авырлыктан соң гына файдалы җиңеллек табыла" ("Инширах (Ачмак)" сүрәсе, 6 нчы аять).

*Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# ЛӘЙЛӘТҮЛ-МИГЪРАҖ

16 ИЮНЬ – МИГЪРАҖ КИЧӘСЕ

**1961 елда Юрий Гагарин космоска очкач, күп кеше моңа ышанмады: илнең куәтле булуын күрсәтү өчен дөнья халкын алдыйлар дип шикләнделәр. Шул вакытта төрле мәҗлесләрдә мөселманнардан: "Сез ышанасызмы соң?" - дип сорагач, алар: "Без 1400 ел элек булган шундыйрак вакыйгага ихластан ышанабыз - пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә әмере белән күкнең 7 нче катына кадәр күтәрелде. Раббыбыз күрсәткән нәрсәләрне күреп кайтты. Шулай булгач, Гагаринның чуен тартмада күкнең беренче катына гына очканына нишләп ышанмаска?" - дип җавап тоттылар.**




Дөрестән дә, үзен мөселман санаган һәр кеше могҗизалы Мигъраҗ вакыйгасын олы хөрмәт белән искә ала, әлеге могҗиза кичәсендә булган бар хәлләргә ихлас ышана.

Гарәп теленнән мигъраҗ сүзе "күтәрелү", "күккә ашу" дип тәрҗемә ителә. Ислам тарихында исә мигъраҗ вакыйгасы Мөхәммәд пәйгамбәрнең (сгв) 7 кат күккә күтәрелүе белән бәйле. Бу хәл 621 елда була.

Рәҗәп аеның 26 нчы көненнән 27сенә каршы төндә Мөхәммәд пәйгамбәр (сгв) Кәгъбәтулла янында йоклап ята. Кинәт ул тавыш ишетә һәм күзен ачкач, Җәбраил фәрештәнең килгәнен күрә. Фәрештә үзе белән Бурак (яшен тизлеге белән йөрүче) исемле ике канатлы атка охшаш җанвар алып килгән була. Мөхәммәдкә (сгв) ул шушы җанварга атланырга куша һәм алар Аллаһы Тәгаләнең олуг рәхмәте белән Мәккәдәге Әл-Хәрам мәчете яныннан Иерусалимдагы изге Әл-Кудс мәчетенә килеп төшәләр. Шунда намаз укыганнан соң, пәйгамбәребез (сгв) Җәбраил фәрештә белән күккә аша.

Күкнең 1 нче катында Мөхәммәд Адәм галәйһиссәлам белән очраша. 2 нче катында Гайсә һәм Яхъя пәйгамбәрләрне (гс) күрә. Күкнең 3 нче катында бик күркәм кыяфәтле, йөзе тулган ай кебек матур кеше белән сәлам алышалар. Бу Йосыф пәйгамбәр (гс) була. 4 нче катта пәйгамбәребезне Идрис (гс) каршы ала. 5 нчесенә җиткәч, Һарун (гс) белән очрашалар, 6 нчыда - Муса пәйгамбәр (гс) белән.

Күкнең 7 нче катында бик күп фәрештәләр була. Алар күк капусын ачалар һәм Мөхәммәд (сгв) куркудан сәҗдәгә китә. Шул вакытта Аллаһтан вәхи килә. Пәйгамбәребез (сгв) Аллаһка мөрәҗәгать итеп: "Әттәхиятү лилләәһи үәссаләвәәтү үәттаййибәәт" ("Тел һәм тән гыйбадәте һәм яхшы гамәлләребез фәкать


*(Ахыры 2 нче биттә.)*

*Мөфти Илдус хәзрәт:*

# "Болгарны тергезергә көч куйганнар өчен догалар кылабыз"

**10 июньдә Болгарда Ислам динен рәсми кабул итү көненә багышланган Болгар җыены үткәрелде һәм Ак мәчет ачылды. Меңләгән милләттәшләребезне туплаган җыенда Ислам хезмәттәшлеге оешмасы генераль сәркатибе Әкъмәлетдин Ихсаноглы, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе, ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Шәйхелислам Тәлгат Таҗетдин, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз катнашты.**



Ак мәчетне ачу тантанасы башланганчы иман йорты ишек төбендә имамнар берберсен алыштырып Коръән укыды. Бу чарадан балалар да читтә калмады. Ак мәчет ачылышына җыелган халык борынгы Болгар җиренең яңаруына, Ислам дине белән тагын да нурлануына куанып Коръән сүрәләрен тыңлады.

Мәчетне ачу тантанасында рәсми затлар, күп сандагы кунаклар чыгыш ясады. Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз рәсми сүзләрне йомгаклап, догалар укыды, Аллаһы Тәгаләдән һәрбарчабызга бәрәкәт, җиребезгә иминлек сорады:

- Безнең, гомумән, тарихыбыз югалганнан соң күз нуры булып сакланып калган Болгар кебек урыннарны тергезергә шушындый көч куйганнары өчен һәрберегезгә, рухи яктан җанландырган кешеләргә дә, бигрәк тә мөфти Тәлгат хәзрәткә, матди яктан көч куйган беренче Президентыбызга һәм хәзерге Президентыбызга багышлап догалар кылабыз. Биредә дә дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән сорыйсы килә: "Я, Раббым, шушы көнгә кадәр безнең халкыбызны мөселман булып яшәттең, адәм балаларыннан яратып хакыйкый инсаннардан кылдың, ризык белән ризыкландырдың, тәннәребезгә сәламәтлек бирдең, акыл-зиһенне, күңелебездән иманны тартып алмадың, я Раббым, шушыларны ахыр Кыяматкә кадәр халкыбызда-милләтебездә дәвам ит, үзебезнең нәсел-нәсәбәләребезне дә иманлы, инсанлы, намазлы, игелекле, тәүфыйклы, һидаятле кылып, һәммәбезгә үзең вәгъдә иткән җәннәтләреңә керергә насыйп ит".

Аннары рәсми затлар яңа мәчетне карадылар. Шуннан соң борынгы Җәмигъ мәчете хәрабәләре сакланган урында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе, ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәмматшин дин әһелләре, җәмәгать белән бергә өйлә намазын укыды.

Өйлә намазыннан соң Президент Рөстәм Миңнеханов һәм башка рәсми затлар, шулай ук чит ил кунаклары Татарстан Диния нәзарәтенең чатырында мөфти Илдус хәзрәт һәм башка дин әһелләре белән бергә әңгәмә кордылар, бәйрәм уңаеннан махсус әзерләнгән пылауны авыз иттеләр.

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге***

# ИҢ МӨҺИМЕ – ҖӘМӘГАТЬ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ



***Марат Низамовның ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты рәисе булып эшли башлавына 3 ай узып китте.***

**- Марат Ренатович, бу вакыт эчендә нинди эшләр башкарылды? Комитет эшенә нинди яңалыклар кертелде? Беренче чиратта нинди сорауларга җавап эзләргә туры килде?**

- Безнең яңа команда алдында торган иң мөһим мәсьәлә - мөселманнарның "Хәләл" комитетына ышанычларын арттыру. Моңа бары тик үз вазифаларыбызны намус белән башкарсак кына ирешеп була. Моның өчен без комитет эчендәге эшне җайга салдык, эшләүчеләрнең вазифаларын билгеләгән инструкцияләр төзедек, яхшылап таныклыкларның, килешүләрнең, тикшерү актларының исәбен алып бара башладык. Комитет штатын тулыландырдык, сертификатлар бирелгән оешмаларның реестрын тикшердек. Кайберләре белән, таныклыкларының гамәлдән чыгу вакыты җитеп килү сәбәпле, без үзара хезмәттәшлекне дәвам итү буенча сөйләшүләр алып бардык. Комитет белгечләре даими рәвештә Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләрендә урнашкан авыл-шәһәрләрдәге җитештерү урыннарына - Чаллыдагы "Челны-бройлер"га, Осиноводагы (Яшел үзән районы) "Казан кошчылык фабрикасы"на, "Казан май комбинаты"на, Чуашстанга баралар. ААҖ "Ак Барс" холдинг компаниясе, "Челны-бройлер", "Казан ит комбинаты", "Сарман-мясо" җитәкчеләре белән алдагы үзара хезмәттәшлекне дәвам итү буенча эшлекле очрашулар үткәрелде. Шулай ук безнең комитет Россиядә "Хәләл" сертификациясе белән шөгыльләнгән башка оешмалар белән дә эш алып бара.

**- Бу вакыт эчендә хәләл продукция чыгаручы оешмаларның саны арттымы?**

- Соңгы айларда комитетка Татарстан, Киров, Түбән Новгород өлкәләре һәм Россиянең башка өлкәләрендә терлек чалу, ит полуфабрикатларын җитештерү, татлы ашамлыклар әзерләү белән шөгыльләнүче оешмалардан "Хәләл" стандарты буенча тикшерү үтүне сорап хатлар килде. "Челны-мясо" кебек яңа партнёрларыбыз да барлыкка килде.

**- Хәләл ашамлыклар барлык кешеләргә дә барып ирешсен өчен сез нәрсә эшлисез? Хәләл ризык өлкәсенә кагылган рәсми оешмалар, дәүләт структуралары, хосусый фирмалар белән мөнәсәбәтләрне ничек төзисез?**

- Без даими эш алып барабыз, очрашулар оештырабыз, хәләл стандартына кагылган агымдагы сорауларга төрле оешмалар белән берлектә җаваплар эзлибез: "KAZAN-HALAL 2012", Татарстан Республикасының инвестицияләр үсеше агентлыгы, Хәләл ризык җитештерүчеләрнең милли ассоциациясе, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе. ЯАҖ "Тест-Татарстан" Республика Сертификация методик үзәгенең генераль директоры Наталья Кондратьева һәм "Хәләл" сертификацияләү органы җитәкчесе Любовь Артамонова белән очрашу вакытында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге оешмаларны хәләл стандарты буенча сертификацияләүдә үзара мөнәсәбәтләр турында фикер алышынды. Идел буе федераль округында "ХЕМА" компаниясе вәкиллеге җитәкчесе Эдуард Әхмәтшин белән очрашу бик кызыклы үтте. Фирма ашамлык һәм эчемлекләрдә дуңгыз ите, мае һәм каны барлыгын тикшерүче бердәнбер тиз башкарыла торган тестлар тәкъдим итә. Без компания җитештергән тестлар һәм яңа продукция белән таныша алдык. Хәләл өлкәгә кагылышлы эшлекле очрашулар вакытында безне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең бердәнбер вәкиле буларак кабул иттеләр.

**- Комитетның тикшерү функциясен ничек итеп камилләштерергә уйлыйсыз? Сездә технологлар-белгечләр бармы?**

- Иң мөһиме булып урыннардагы җәмәгать күзәтчелеге тора. Без Татарстан мөхтәсибәтләре белән тыгыз элемтәдә эшләргә җыенабыз. Моннан тыш, безнең эш барышында терлек чалуга һәм чимал эшкәртүгә кагылышлы сораулар туа. Комитетта хәләл буенча эксперт-технолог вазифасын башкаручы хезмәт урыны булдырылды. Шулай ук без эш барышында барлыкка килгән актуаль сораулар буенча ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы белән тыгыз элемтәдә торабыз.

**- Яңартылган "Хәләл" комитетының башлангыч эш этабында сезгә нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килде?**

- Кызганыч, ләкин хәләл ризык җитештерү арткан саен, "хәләл" брендын җитештерү өлкәсендә дә, җәмәгать туклануы өлкәсендә дә нигезсез куллану очраклары арта тора. Ислам дине кануннарын һәм хәләл ризык җитештерү кагыйдәләрен белмәү сәбәпле, кайбер оешмалар чималны эшкәртү технологиясен боза. Ситуацияне үзгәртү өчен якын киләчәктә без үз алдыбызга хәләл продукциясе җитештерүче оешма хезмәткәрләрен укыту-өйрәтү, ә сәүдә һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә җәмәгать контролен көчәйтү бурычын куябыз.

***Фәрит БАТЫРШИН***

# ЛӘЙЛӘТҮЛ-МИГЪРАҖ

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

Аллаһыбыз өчен"), - дип хәмед әйтә. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә: "Әссәләмү галәйкә әййүһәннәбиййү үә рахмәтүллаһи үә бәрәкәәтүһү" ("Йә пәйгамбәр, сиңа Аллаһның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын"), - дип җавап бирә. Расүлебез: "Әссәләмү галәйнәә үә галәә гыйбәәдилләәһиссаалихиин" ("Сәлам безгә һәм гыйбадәттә булып, изге гамәлләр кылучыларга"), - дигәч, барлык фәрештәләр: "Әшхәдү әлләә иләәһә илләә Аллаһү үә әшхәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһү" ("Таныклык бирәм ки, юк иләһ Аллаһтан башка һәм таныклык бирәм ки, Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе"), - дип әйтәләр.

Шулай итеп, намазларда укыла торган "Әттәхият" зикере - Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәребез белән Мигъраҗда сөйләшүеннән хасил булган мөкатдәс сүзләр...

Риваятьләргә караганда, шунда - 7 нче кат күктә - Мөхәммәд Мостафа (сгв): "Йә Раббым, Мигъраҗ могҗизасы белән мине нигъмәтләндердең, өммәтем өчен дә шундый бер нигъмәт теләр идем", - дип әйтүенә Аллаһы Сүбеханәһү вә Тәгалә: "Мөэминнең мигъраҗы - намаздыр", - дип җавап бирә. Белүебезчә, нәкъ менә мигъраҗ сәфәрендә Мөхәммәд (сгв) өммәтенә, ягъни мөселманнарга 5 вакыт намаз фарыз ителә һәм кем дә кем намазларын төгәл үтәсә, пәйгамбәребез (сгв) Мигъраҗ кылып Аллаһы белән очрашкан кебек, шул кеше дә Раббысы белән очрашып сөйләшкән кебек зур дәрәҗәләргә ирешер һәм бик күп савапка ия булыр. Шуңа күрә мөселманнар Мөхәммәд пәйгамбәр (сгв) Мигъраҗдан алып кайткан 5 намаз кылу мөмкинлеген Аллаһның олуг бүләге буларак кабул итә. Шул 5 вакыт намаз, беренчедән, әҗер-савап чыганагы булса, икенчедән, ул мөэминнәр тормышының камил һәм нык терәге.

Үз эченә "Әттәхият"не алган намаздан тыш, Мигъраҗ кичәсендә мөселманнарга тагын ике бүләк бирелде: пәйгамбәребезгә (сгв) Кыямәт көнендә үз өммәтен яклау хокукы (шәфәгать кылу мөмкинлеге) һәм "Бәкара" сүрәсенең ахырына өстәлгән 2 аять. Шушы 2 аять искиткеч яхшы дога да булып санала: "И Раббыбыз! Көчебез җитмәслек, сабыр итә алмаслык авырлыкларны безгә йөкләмә! Безне гафу ит, ярлыка һәм дә рәхмәтеңне насыйп кыл!.." Хәдистән белүебезчә, кайсы өйдә "Бәкара" сүрәсенең ахыргы ике аяте укылса, шайтан шул өйгә 3 көн якын килә алмас. Мөхәммәд (сгв) шулай ук әйтте: "Кем әлеге ике аятьне йоклар алдыннан укыса, аңа шул җитә" (шул кеше һәртөрле явызлыктан имин була).

... Мигъраҗда Аллаһ рәсүленә (сгв) камил тәһарәт алу тәртибе өйрәтелде һәм җәннәт белән җәһәннәм күрсәтелде. Оҗмах һәм тәмугны карагач, Мөхәммәд (сгв) туган Мәккә шәһәренә әйләнеп кайта.

Мигъраҗ вакыйгасыннан соң пәйгамбәребез (сгв) көлми башлый - көләсе урынга елмая гына. Күп очракта елый. "Мин күргәнне күрсәгез, елмая да алмас идегез", - дип әйтә торган булган ул сәхабәләргә.

Әйе, заманында Гагаринның космоска очуы могҗиза, ышанмаслык хәл буларак кабул ителсә дә, Мөхәммәд галәйһиссәламнең мигъраҗы белән чагыштырганда, ул әллә ни зур нәрсә түгел, чөнки пәйгамбәребез ахирәткә ашкан, күкнең җиденче (!) катына ирешеп, аның капусы ачылуын күзәткән. Ә космонавтлар күккә җирдән чагыштырмача бик аз гына ераклыкка күтәрелеп, галәмнәрнең беренчесе белән генә бераз таныша (белгечләр раславынча, барлыгы 18 мең (!) галәм бар). Космоска очып беренче галәмне күзәтү мөмкинлеген дә Аллаһы Тәгалә кешеләргә үз бөеклеген һәм кодрәтен күрсәтү өчен бирә.

Бүген үлем, ахирәт, җәннәт белән җәһәннәм турында сүз чыкса, кайберәүләр шикләнеп: "Кем кайткан соң әле аннан?" - дип сорый. Янәсе, барып кайтучы булса, сөйләүчегә ышаныр идек. Мигъраҗ вакыйгасын күздә тотып, без бер дә икеләнмичә, туры әйтә алабыз: "Бар андый зат! Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) барып кайткан!" Әйе, ул күкнең җиде катында да булып, ахирәтне, оҗмах һәм тәмугны күргән, гыйбрәтле вә хикмәтле хәлләрнең шаһиты булган. Кайткач исә сәхабәләренә бик еш әйтә торган булган: ахирәт тормышыгызны кайгыртыгыз, җан биреп, шунда барачагыгызны онытмагыз!

Хәзер дә без шушы нәсыйхәтне кабатларга, бер-беребезгә искә төшереп торырга тиеш. Моның турында уйланмасак, ахирәтне кайгыртмасак, үкенечле булуы ихтимал. Шуңа да, җәмәгать, әзерләник, дөнья өчен тырышкан кебек мәңгелек ахирәт тормышы өчен дә тырышыйк, шунда күчәсебезне онытмыйк.


***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе директоры***

**Бер ел эчендә төзелеп, 10 июнь көнне ишекләрен ачкан яңа иман йорты - Ак мәчет Идел буе Болгарына якты бер нур бирде. Аны ачу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе, ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев: "Ак мәчет ниятләрнең чисталыгын күрсәтә. Бу хакта истә тотарга кирәк", - дип белдерде. Иман йорты ишек төбендә тәүге догаларны әйтеп, Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз иман йортын булдыручыларга рәхмәтен җиткерде.**

Мәчеттән тыш мөфти хәзрәтләренең резиденциясе һәм мәдрәсәдән торган Ак мәчет комплексы Болгар музей-тыюлыгының Көньяк капкасы янында төзелгән. Ул борынгы татар авылы итеп ясалган комплекс белән янәшәдә.

Мәчет бинасы өч гөмбәз һәм 46,5 метр биеклектәге ике төз манарадан тора. Төп гөмбәзнең диаметры - 10 метр. Ә мәчет эчендәге гөмбәз биеклеге - 17 метр. Аның барабанында төсле пыялалардан торган 16 тәрәзә урнаштырылган. Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, мәчет манаралары Мәдинә шәһәрендәге Мөхәммәт пәйгамбәр мәче-

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ҖАН СЕРДӘШЕ – ЙОСЫФ КИТАБЫ



**Урта гасыр ядкярләреннән татар әдәбияты тарихына Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" дастаны кебек тирәнтен тоташкан бүтән әсәр, мөгаен, юктыр. Идел буе шигъриятенең XIII йөздән соңгы бөтен үсеш юлы шушы поэма традицияләре белән сугарылган. "Кыйссаи Йосыф" - татар халкы аны "Йосыф китабы" дип йөртә - болгар-татар әдәбиятының безгә исән-имин килеп җиткән иң борынгы ядкяре.**

Шәһри Болгарда 1299 елда куелган кабер ташында Кол Гали әсәре каһарманының улы "Мамил" исеме теркәлгән. Шунысы кызык, дастанның тәгәлләнү елы белән таш куелу датасы арасында уртача бер кеше гомере озынлыгына тиң вакыт ята. Бу исем Идел-Чулман Болгарстанының төрле чорга караган җиде ташында очрый.

Кол Галинең тормыш юлына кагылышлы мәгълүматлар, күп кенә урта гасыр авторларыныкы сыман ук, сакланмаган. Аның Идел буенда туып, Харәзем якларында белем алуы һәм мөдәррислек итүе турында кайбер мәгълүматлар гына бар. Болгар дәүләтен монголлар басып алганда һәлак булган дип гөман кылына. Әлеге мәзкүр әсәрен ул 1233 елның 12 маенда, үзе язганча - 630 елда рәҗәп аеның 30 ында тәмамлаган.

Идел буе төрки әдәбиятының барлык мөһим ядкярләрендә бу дастан теленең һәм фәлсәфи-сәнгатьчә яңгырашының тәэсирен гасырдан-гасырга күзәтергә мөмкин. Яңа дәвер татар шигъриятендә ул йогынты Тукайгача һәм соңгы чор шагыйрьләренәчә сузыла. Әсәр татар күчереп язучыларының армасталмас эшчәнлеге һәм Казан басмалары аркасында безгә килеп җиткән. Бүгенге көнгә аның табылган күчермәләре саны 300 гә якын. 1839 елдан 1918 елга чаклы ул 80 тапкыр диярлек басылып чыккан. 1983 елда "Кыйссаи Йосыф"ның күренекле тел галиме Ф.С. Фәсиев тарафыннан эшләнгән тулы тексты дөнья күрде.

Кол Гали әсәре гасыр ярымнан артык татар, төрек, рус һәм Европа галимнәренең игътибарын җәлеп итеп килә. Аның теле, язылу ватаны, халыкта таралышы һәм кайбер шигъри үзенчәлекләре Г.Флейшер, В.Перч, Ш.Мәрҗани, М.Һоутсма, К.Броккельманн, М.Күпрелезадә, Г.Рәхим, А.Самойлович, Е.Бертельс, Г.Таһирҗанов, Ә.Нәҗип, Х.Күроглы һ. б. хезмәтләрендә тикшерелә.

Татар филологиясендә дастанны махсус тикшерү эшен Җ.Алмаз башлап җибәрде. Татар әдәбият белемендә һәм фольклор фәнендә бу теманы эшләүгә Б.Яфәров, М.Гайнуллин, Х.Госман, Г.Халит, Н.Юзиев, Ш.Абилов, Х.Мөхәммәдов, И.Надиров, М.Җәләлиева, С.Шәйдуллин, Р.Ганиева, Х.Миңнегулов, Р.Әмирханов төрле дәрәҗәдә өлеш керттеләр. 1979 елда Мәскәүнең "Наука" нәшриятында һәм 1984 елда Казанда безнең дә әсәрне әдәби ядкяр буларак тикшерүгә багышланган монографик хезмәтләребез дөнья күрде. 2001 һәм 2006 елда аның халыкара кыйммәтен яктырткан яңа монографияләребез басылып чыкты.

"Кыйссаи Йосыф" дөнья әдәбиятында, аеруча Көнчыгыш әдәбиятларында, Йосыф сюжетына язылган күпсанлы әсәрләрнең бер төрдәше санала. Әмма төрки әдәбиятларда ул - Йосыф темасына язылган иң беренче дастан. Бу әдәбиятлар өчен аның гаять зур әһәмияте дә шушы бәрәкәтле сюжетны төрки укучылар өчен дә рухани ләззәт чыганагы итүгә бәйле. Кол Галидән соң төрки әдәбиятларда, башлыча госманлы төрекләре әдәбиятында, әлеге әсәрнең яңадан-яңа төрдәшләре дөньяга килә.

Идел буе шагыйренең Йосыф сюжетын эшкәртүгә керткән барлык яңалыкларын аның Кече Азиядәге дәвамчылары тулысынча күтәреп алалар. Болгар-татар әдәбиятында исә "Кыйссаи Йосыф" бу темага язылган бердәнбер шигъри әсәр булып кала, һәм ул татар укучыларының яңадан-яңа буыннарына эстетик тәрбия биреп, зәвекъләрен канәгатьләндереп килә. Әсәрнең мондый даны аның халыкчан шәкленә, фикер һәм мотивларның инсанчылыгына бәйле. Аңарда халыкның киң катлауларына якын булган тыныч һәм бәхетле тормыш хыялы чагыла.

Шагыйрь әсәрнең үзәгенә хөкемдар һәм халык бәхете проблемасын куя. Калган барлык мәсьәләләр иҗтимагый, әхлакый, эстетик планда шушы үзәк тирәсенә туплана.

Проблема каһарман образы аша хәл ителә. Хөкемдар шәхесе нинди булырга тиеш? Шагыйрь шул сорауга җавап бирү өчен каһарманны бала чагыннан алып төрле сынаулар аша уздыра, шулар аша аның кешелек сыйфатларын ача.

Кол Гали әсәрендә Йосыфның хәлиткеч сыйфаты итеп тугрылык тасвирлана. Сюжетның Көнбатыш версияләрендә каһарман даимән "Гүзәл Йосыф" дип аталса, "Кыйссаи Йосыф"та ул - "Йосыф Сыйддыйк", ягъни Тугры Йосыф.

Тугрылык дигәндә шагыйрь барыннан да элек атага тугрылыкны күздә тота. Бу мотив каһарманның төш юратуыннан башланып, атасы белән янә күрешүенә чаклы үстерелә. Әсәрдәге төрле шартларда аның бу сыйфаты антка, бурычка тугрылык, ахыр чиктә, туган халкына, аның гореф-гадәтенә тугрылык рәвешен ала.

Йосыф язмышындагы иң кискен очрак - Зөләйхә вәсвәсәсенә бирешми калу да - "Кыйссаи Иосыф"та Аллага һәм, әлбәттә инде, атага тугрылыкны сынау төсен ала. Йосыфны сатып алгач, бары Кол Гали поэмасында гына Мисыр газизе Кыйтфир Зөләйхәгә: "Безим бу углымыз улсун имди", - ди. Шушы факт Йосыфның Зөләйхә каршында үз-үзен тотышына бөтенләй башка яңгыраш бирә. Хатынның юмарт мактаулары, үгет һәм ялваруына карамастан, каһарман үтә акыллы һәм тыныч итеп: "Бәни ул угыллыкка кабул кылди, Атама нәтә хаин улам имди", - дип җавап бирә. Бу инде колның хуҗага тугрылыгыннан күп өлеш мәгънәлерәк, кешелеклерәк. Шулай итеп, шагыйрь каһарманның яңа иҗтимагый халәтенә ата-угыл мөнәсәбәтен күчерә. Ә инде Йосыф, Зөләйхә сүзләреннән эреп, елмаеп куйгач, аны хата эшләрдән кисәтеп, күз алдына атасы Йагъкуб килеп баса, һәм егет үзендә яңадан ныклык таба. Атасының истәлеге һәрвакыт аның вөҗданы сагында тора. Сюжетка төрки шагыйрь алып килгән шундый нюанслар әсәргә яңачарак, үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Тугрылык идеясе - "Кыйссаи Йосыф" поэмасының лейтмотивы. Бу әхлак сыйфаты кешенең бәхеткә ирешүе өчен төп шарт икәнне шагыйрь Зөләйхә язмышы белән раслый. Әсәрнең хатын-кыз каһарманы, кырык ел тугрылык саклап, сабыр итүе нәтиҗәсендә Йосыфка тиң һәм лаек була.

"Кыйссаи Йосыф" - борынгы төрки поэзиянең сюжетлы беренче әсәре. Аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр дә шуңа бәйле. Әле сюжетлы әсәр коруда төрки әдәбиятның мөстәкыйль казанышлары җитәрлек булмаганлыктан, шагыйрь фольклор тәҗрибәсенә таяна. Сурәтләрне эшләү, сюжет борылышларын кору, стилистик ялгамнарны тәэмин итүдә ул тылсымлы әкият һәм каһарман эпос тәҗрибәсеннән файдалана. Аның сәнгатьчә фикерләве дә нигездә эпик поэтика кысаларында бара.

Әсәрнең иң әһәмиятле эстетик мәсьәләләреннән булган каһарман проблемасын хәл итүне алыйк. Монда шагыйрь эпик идеаллаштыру кануннарына буйсына.



Йосыфны уңай герой итеп күтәргән төп сыйфатлар - ул тугрылык һәм зирәклек. Ә инде матурлыгы - аның тумыштан бирелгән һәм дөньякүләм данын тотып торган үзенчәлеге. Мисырда аны кабат сату вакытында базар хәбәрчеләре ун сыйфатыннан берсе итеп батырлыгын да телгә алалар:

***Алтынчы: камулардан бик куәтлү -***
***Кырык ирдән куәти артык имди.***

Әсәр эчендә Йосыфка физик көч күрсәтү бөтенләй кирәк тә булмый. Әмма шагыйрь төрки укучының каһарман дастаннар традициясендә тәрбияләнүен истән чыгармый: ә аларда геройның беренче сыйфаты - батырлык.

Эпик идеаллаштыруның иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булып магик көчкә - тылсымга ия булу санала. Эпоста бу каһарманның өстенлеген тәэмин итү өчен кирәк. Кол Гали поэмасында Йосыф та шул сыйфатка ия итеп тасвирлана. Мәсәлән, Кодес (Иерусалим) бәге, Йосыфны алып калу өчен, кәрван артыннан куа чыккач, каһарманның бер күз карашыннан ул 12 меңле гаскәре белән өч көнлек йокыга тала.

Йагъкуб сурәтендә дә эпослардагы зирәк аксакал гәүдәләнә. Бу, барыннан да элек, аның фикер йөртүендә, сөйләмендә чагыла. Үгет бирәме ул, кисәтәме, үз-үзен тынычландырамы - һәр очракта аның сүзләре мәгънәле, гыйбрәтле.

Зирәк аксакалның үлемен тасвирлаганда, Дәдә Коркыт турындагы легендаларга һәм угыз-кыпчак дастаннарына хас мотивлар килеп керә. Йосыф сюжетына Кол Галидән элек иҗат ителгән әсәрләрдә Йагъкубның тере көе үзенә кабер казучыларга юлыгуы тасвирланмый. Бары "Әнисел-мөридин"дә генә аның мәетен бабалары күмелгән мәгарәгә алып килүләре һәм, шартлы сүзләр белән эндәшкәч, мәгарә ишеге ачылып, эчкә кертүләре языла.

"Кыйссаи Йосыф"та исә Йагъкуб, туган җиренә кайтып барышлый, кабер казучы фәрештәләргә тап була, кабернең эчен күрергә дип кереп китә һәм шунда җан бирә. Бу - Дәдә Коркытның үлемнән качып йөргәндә дөньяның дүрт тарафында да үзенә кабер казучыларга юлыгуы хакындагы легендаларны хәтерләтә. Себер татарларыннан язып алынган "Ак Күбәк" дастаны каһарманның атка атланган көе кабергә кереп китүе һәм шунда күмелүе белән тәмамлана. Ак Күбәкнең кабер казучылар белән сөйләшүе гаҗәп дәрәҗәдә Йагъкубның фәрештәләр белән әңгәмәсенә охшаган. Шунысы кызык, кешенең кабер казучыларга юлыгуы һәм тере көе кабергә керүе турындагы легендалар Татарстан авылларында хәзер дә очрый. Күп санлы шушындый детальләр Кол Гали поэмасына төрки колорит бирә һәм сюжетның төрки җирлектәге үзенчәлекле сәнгатьчә яшәешен тәэмин итә. Зөләйхә, мәсәлән, Йосыфның чәчен толымлап үрә. Йосыф сюжетының Кол Галигә кадәрге чыганакларында бу деталь бөтенләй юк, һәм ул булырга мөмкин дә түгел. Чөнки, затлы нәсел күрсәткече буларак, ирләрнең толым йөртүе борынгы төркиләргә хас күренеш. Соңрак Рабгузиның "Кыйссасел-әнбия"сендә дә Йосыф толымлы итеп сурәтләнә. Бу очракта Кол Гали кыпчак мохитенә якынрак тора.

***(Ахыры газетабызның киләсе санында.)***

***Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,***
***филология фәннәре докторы, профессор***

# Ак мәчет ниятләр чисталыгын күрсәтә

те манараларына охшатып ясалган. Болгарга килүчеләр үзләрен шул изге мөселман җирендә булып кайткан кебек хис итәчәк.

Мәчет диварлары традицион декоратив элементлар - лалә чәчәге, арабеска, мукарнас һәм геометрик орнаментлар белән бизәлгән. Биеклеге 4,5 метр булган төсле пыялалы тәрәзәләр бинаның эчендә аерым бер күркәмлек тудыра. Ике өлештән торган гыйбадәт бүлмәсендәге барлык мәйдан бертигез яктыртыла. Бер үк төстә булган дивар һәм гөмбәзнең агачтан эшләнгән элементлар белән бизәлүе үзенә күрә бер матурлык өстәп җибәрә.

Гыйбадәт бүлмәсенең мәйданы - 180 квадрат метр. Антресоль мәйданы 100 квадрат метрны тәшкил итә. Намаз бүлмәсендә диаметры 25 метрлы люстра эленгән.

Мәчетнең төп ишеген әйләндереп торучы 20 колонна ярымай рәвешендә ясалган.

Биналар каре формасында урнашкан. Мусалла, ягъни 1500 квадрат метрлы ачык урында урнашкан гыйбадәт мәйданы, 88 колоннадан торган арка белән әйләндерелгән. Аны парктан 5 баскыч аерып тора. Ишек янында намаз алдыннан тәһарәт алуны символлаштыручы фонтан бар. Ачык һавадагы арка бирегә килүчеләргә табигать матурлыгын һәм борынгы Болгардагы археологик казылмалар күренешен ача.

Мәчет каршындагы мәйдан гранит белән түшәлгән. Киләчәктә комплекс янына җиләк-җимеш агачлары, чәчәкләр утырту күздә тотыла. Шулай ук Ак мәчет комплексын чагылдырып торачак күл ясау да ниятләнә.

Мәчет төзелешенә 35 тән артык оешма җәлеп ителгән. Төзү эшләренә барлыгы 1000 нән артык кеше катнашкан. Бер үк вакытта 350 дән артык кеше эшләгән вакытлар да булган. Төзүчеләр хезмәте аеруча мактауга лаек. Мактауларның иң зурысы - Беларусь белгечләренә. Проект авторы Сергей Шәкүров сүзләреннән күренгәнчә, "Исакидис Гранитис" оешмасы архитектура детальләрен ясау һәм монтажлау, бинаның тышын мәрмәр һәм гранит белән ябыштыру кебек эшләрне кыска вакыт эчендә югары сыйфат белән иҗади башкарып чыккан.

Ак мәчет төзелешендә күп төрле материаллар кулланылган. Мәсәлән, катлаулы бизәкләр төшерелгән имән ишекләр, Тиффани техникасы нигезендә ясалган төсле пыялалар. Гөмбәзе үзенчәлекле полимер материаллардан тора. Төзелештә "Боттичино семиклассико" мәрмәре кулланылган. Иман йортын эчтән һәм тыштан бизәү өчен 1200 тонна ак мәрмәр кирәк булган. Мәчетне мәрмәр һәм гранит белән тышлау да катлаулы эшләрдән санала. Манара спираль рәвешендәге мәрмәр кисәкләр белән бизәлгән, һәр кисәкнең уртача авырлыгы - 250 килограмм. Гомумән алганда, манараның йөзлеге 900 кисәктән тора.

Төзелешнең иң җаваплы этапларының берсе - мәчет манарасын кую булган, чөнки манараның биеклеге - 46,5 метр.

# Зәкят — байлар гыйбадәте

**"Зәкят" хәйрия фондының төп эшчәнлеге - Татарстанда зәкят җыю һәм мохтаҗларга таратуның уңайлы системасын булдыру. Әлеге максаттан "Дәүләт хезмәтләре" (госуслуги) электрон порталында акча күчерү схемасы каралган.**


... Аллаһы Сүбхәнә вә Тәгалә байларны мал-мөлкәт белән сыный. Коръәндә әйтелгәнчә, мал-мөлкәт - дөнья хәятенең зиннәте, бизәге. Ләкин бу зиннәттә фәкыйрь-мескеннәрнең дә өлешләре бар. Ул ЗӘКЯТ дип атала.

Бер кеше дә үзе теләп ятим-мескен хәленә калмый. Адәм баласы Раббыбыздан булган сынаулар - янгын, фаҗига, авыру һ. б. белән сынауга дучар ителә.

Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, ди халкыбыз. Тәнебез сәламәт, тормышыбыз иркен, көч-куәтебез ташып торганда ятим-мескеннәргә ярдәм итәргә тырышып яшәсәк иде.

Фотода: Тәтеш районы Кече Әтрәч авылында узган елның июнь аенда Хәлил хәзрәт Мәгъсүмовның йортында яшен сугудан янгын чыга. Нигез тулысынча янып бетә. Яңа нигез кору өчен "Зәкят" фонды да үз өлешен кертте.







# Агачтан могҗиза тудыручы

**Дан тиз тарала, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Илфатны эзләп, аңа заказлар бирергә Яңа Комазанга төрле җирләрдән киләләр.**

Авыл халкы, кирпеч өйләр җиткерсә дә, челтәрләп кырып ясалган тәрәзә йөзлекләре куюын дәвам итә. Халыкның матди хәле күтәрелгән саен зәвыгы да үсә, капкаларын, өй кыекларын тагын да матуррак бизәкләр белән эшлисе килә. Осталарыбыз да камилләшә бара. Алар яңадан-яңа бизәкләр уйлап чыгаралар. Илфат Низамов та: "Барган җиремдә күргән элементларны хәтеремдә калдырырга тырышам. Кайткач башта кәгазьгә төшерәм. Аннан агачка күчерә башлыйм", - ди. Интернеттан да байтак кына кызыклы бизәкләр тапкан ул. Аларны мәдрәсәгә стенд ясаганда да кулланган. Ихлас күңелдән, берсеннән-берсе кызыклы бизәкләр кулланып ясаган тәрәзә йөзлекләре, журнал өстәлләре, китап киштәләре, шкафлар чын сәнгать әсәрләренә әйләнәләр. Мондый агач эшенә осталык әтисе Дамирдан күчкәндер аңа. Ул яшьрәк чакларында Киров өлкәсе авылларына эшкә чыгып йөргән булган. Илфатның кул эшенә һәвәслеге Келәүш урта мәктәбендә укыганда күренә башлый. Куян оялары ясый ул үзләре өчен. Казанда мәдрәсәдә укыганда да остаханәдә шөгыльләнергә ярата. Бүген үзенә умарталар, аларга рамнар да әзерли. Егермеләп баш умарта тота Низамовлар гаиләсе. Һәр зур елга кечкенә инештән башлана, дигәндәй, Илфат та йорт кирәк-яракларын үзе ясау теләге белән агач эшкәртү кораллары сатып алган булган. Иң беренче эшләгән әйберсе - журнал өстәле. "Аны ясаганда бармакларны уйдырып алган идем", - дип искә ала ул. Осталык эшли-эшли килә шул. Төрле заказларга тотынган саен башка төрле инструментлар кирәге дә ачыклана. Эш кораллары янына лобзик, кул фрезасы, шлейфовать итә торган машина да өстәлә. Чимал итеп күбрәк юкә агачын куллана. Чөнки ул нарат, чыршы кебек ярылмый, рәхәтләнеп төрле фигуралар кыяфәтенә кертеп була. Заказлар арткан саен мастерское да кысанлана бара. Хәер, тәрәзә йөзлекләренә, ишекләргә, төрле мебельләргә вакытын бушка уздырмас өчен тотына кебек ул. "Бик тырышсаң, тәрәзә йөзлеген бер көндә ясап була", - ди. Алар белән үзенә акча эшләүне максат итеп куймаган. Төп эше дә үтә җаваплы бит. Яңа Комазанның Рәшидә мәчетендә имам вазифасын башкара Илфат. Авылның олысына һәм кечесенә иман нуры иңдерә. Шулай да аңа Чаллыдан, Санкт-Петербург якларыннан заказлар килә тора. Нинди генә кызыклы бизәкләр кулланмый ул үзе ясаган әйберләрдә. Аларның кайберләре чын могҗизага тиң. Тагын бер осталыгы бар икән Илфатның. "Мичләр дә чыгарам", - ди ул.

***Минневәрис МИНГАЛИЕВ,***
***Мамадыш шәһәре***









## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 16.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:41 | 21:31 | 23:01 |
| Якшәмбе | 17.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| Дүшәмбе | 18.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| Сишәмбе | 19.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:42 | 21:32 | 23:02 |
| Чәршәмбе | 20.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| Пәнҗешәмбе | 21.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| Җомга | 22.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |
| Шимбә | 23.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:43 | 21:33 | 23:03 |


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №24 (141) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-538.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 14 июнь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**